**Г.Р. Мугтасимова, А.Ш. Юсупова**

*Казан федераль университеты, Казан*

# РУС ӘКИЯТЛӘРЕНДӘГЕ СЫЙФАТЛАРНЫ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘ ИТҮНЕҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Публикация статьи осуществлено при финансовой поддержке РГНФ и Правительства Республики Татарстан, проект № 14-14-16014 а(р) / 2014 (РГНФ)

*Эта статья посвящена проблемам литературного перевода с русского языка на татарский язык. Рассмотрены критерии качественного перевода прилагательных, трудности перевода сказок на примерах.*

*This article is devoted to the problems of literary translation from Russian into Tatar language. Considered criteria for high quality translation of adjectives, the difficulties of translation of fairy tales for examples.*

*Ключевые слова: перевод, сказка, прилагательные, троп.*

«Төрле халыкларның әкиятләрен күзәткәндә, алардагы сюжет һәм мотивларның бер-берсенә охшашлыгы игътибарны җәлеп итә» дип яза Л. Җамалетдинов. [2: 45] Академик А.Н. Веселовский күрсәткәнчә, кешелек үсешенең беренче чорларында көнкүреш яки психологик шартларның охшашлыгы, бердәйлеге нәтиҗәсендә күп кенә охшаш мотив һәм сюжетлар мөстәкыйль рәвештә барлыкка килә алган. [2: 45] Шуңа күрә хәтта географик яктан бер-берсеннән бик ерак торган халыкларның әкиятләрендә дә охшаш урыннар очрый. Болар – типологик характердагы уртаклыклар. Халыкара сюжетлар нигездә шул юл белән барлыкка килгән.

Ләкин әкиятләрдә уртаклык никадәр зур булмасын, аларда теге яки бу халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләре дә чагылмый калмый. Мондый үзенчәлекләр күбесенчә геройларның характерында, сөйләмендә, табигать күренешләрендә, көнкүреш детальләрендә ачык күренә. Ниһаять, милли үзенчәлекне аерым мотив һәм сюжетлар да тәшкил итә.

Бу үзенчәлекләрне рус әкиятләренең татарчага тәрҗемәләрендә дә күзәтергә мөмкин. Икетеллелек, катнаш никахларның күбәюе, урбанизация процессы – болар тәрҗемәне мәҗбүриләштерүче көчләр. Балаларга әкият

сөйләгәндә, еш кына кайсы халык әкияте икәнен дә тәгаенләп тормыйбыз, чөнки руслар белән татарлар дүрт гасыр вакыт эчендә мәдәни яктан шулкадәр тыгыз бәйләнештә яшиләр ки, хәтта кайбер үзенчәлекләрне сизеп тә булмый. Төп аерма - геройларның исемнәрендә, әкиятнең башлам һәм йомгак өлешләрендә.

Тәрҗемәчеләр өчен иң зур авырлык тудыра торган сүз төркемнәре арасында сыйфатлар да бар, чөнки төрле телләрдә бу сүзләр төрле мәгънә төсмере белдерә. Сыйфатларны дөрес кулланмау әкиятнең мәгънәсен боза, ә сыйфатларны төшереп калдырсаң, текстның эстетик эшләнеше югары дәрәҗәдә булмый.

Сыйфат ул – стилистик чара, ә теләсә кайсы стилистик чара экспрессив мәгънәгә ия. Хәтта кайвакыт стилистик яктан нейтраль тел чаралары да экпрессив мәгънәгә ия булырга мөмкин. Тәрҗемәче чыганакның стилистик үзенчәлекләрен дә, экспрессив үзенчәлекләрен дә истә тотып эш итәргә тиеш.

Рус әкиятләрен татарчага тәрҗемә иткән вакытта сыйфатларны тәрҗемә итүнең дүрт ысулы булуы ачыкланды. Беренче ысул белән эш иткәндә, чыганак телдәге сыйфат икенче телгә төп номинатив тәңгәллекләре белән күчерелә. Болай эшләгәндә, чыганакның күчерелмә мәгънәсе дә, образлылыгы да тулысынча саклана. Беренче ысул белән тәрҗемә итү өчен, төп шарт – калькалаштырылган сыйфат табигый, эмоциональ-экспрессив булу. Сыйфатларны русчадан татарчага тәрҗемә практикасында бу ысул киң кулланыла. «Колобок» әкиятенең татарчага тәрҗемәсендә кайбер мисалларны карап үтик: Не ешь меня, **серый** волк! - Син мине ашама,..**соры** бүре, мин сиңа җыр җырлармын; Где тебе, **косолапому,** съесть меня - Кайда ул сиңа, **Кыйшык аяк,** мине ашарга! Шунысы кызык: русча-татарча сүзлектә «косолапый» сыйфаты татарчага «чылыш аяк» дип бирелгән (Русско-татарский словарь. – Москва: Русский язык, 1984. – С.232. )

Сүзгә-сүз тәрҗемә төп мәгънәле тәңгәллекләрнең төзелешләре, сүз төркемнәре буенча туры килүен күздә тотмый. Монда бер сүз төркеме икенче сүз төркеме белән алмаштырылырга һәм башка грамматик үзгәрешләр булырга

мөмкин. Мондый үзенчәлек рус әкиятләрендәге сыйфатларны тәрҗемә иткәндә дә күзәтелә. Мәсәлән, Был тот Дед в **мохнатые** ветки одет, в волосах шишки **еловые**, в бороде шишки **сосновые**, **седые** усы до земли висят, глаза огоньками горят. («Кот – Воркот») – Үзе ылыс бөртегенә төренгән, чәченә **чыршы**, сакалына **нарат** күркәләре ябышкан, **чал** мыегы җирдән сөйрәлә, күзләре **яшел** уттай ялтырый, ди, моның. («Мырау Батыр») Чыганак әкияттәге «мохнатые» сыйфаты татарчага гомумән тәрҗемә ителмәгән булса, «еловые» һәм «сосновые» берәмлекләре «чыршы», «нарат» сүзләре белән бирелә.

Әкиятләрдә сыйфатлар троплар төзүдә катнашалар. Бу очракта һәр сүзне бер телдән икенче телгә һәрвакытта төп мәгънәсендәге тәңгәллекләре белән генә күчереп булмый. Сурәтләү чарасы икенче телдә табигый яңгырасын, эмоциональ-экспрессив булсын өчен, еш кына аның образ ясауда беренче дәрәҗәдә булмаган сүзләрен үзгәртергә, төшереп калдырырга, яңа сүзләр өстәргә туры килә. Чыганакның образ төзү өчен иң әһәмиятле компонентларын төп мәгънәсендәге тәңгәллекләр белән биреп, кайбер сүзләрен берникадәр үзгәртеп тәрҗемә итү күздә тотыла. Мондый үзгәрешләр сыйфатларны тәрҗемә иткәндә дә кулланыла. Мәсәлән, Выросла репка **большая-пребольшая.** («Репка») – Шалкан көн үсте, төн үсте, **бик зур** булды, күперде. («Шалкан»); Шубка **шелковая**, хвост **золотой**, глаз **огневой** – ах, хороша Лисичка-сестричка. («Кот-воркот, Котофей Котофеевич») – Туны **ефәктәй елкылдый**, көлтә-көлтә койрыгы **алтындай ялтырый**, күзе **уттай яна** – ай-һай матур-күркәм Төлке Түләкәй. («Мырау батыр») Күргәнегезчә, «большая-пребольшая», «шелковая», «золотой», «огневой» сыйфатын татар теленең стилистик нормаларына зыян китермичә, төп мәгънәле тәңгәллекләр белән генә тәрҗемә итеп булмый. Шуңа күрә «Выросла репка большая-пребольшая» җөмләсен татар теленең үзенчәлекләренә яраклаштырып (сүзләр өстәп), шул ук вакытта чыганакның күчерелмә мәгънәсен һәм образлылыгын саклап, берникадәр үзгәртергә туры килә.

Һәр телдә бик күп вакытлар шушы тел ияләре генә кулланып килгән һәм аларга гына аңлаешлы гадәти үзенчәлекле сурәтләү чаралары була. Андый

очракта сыйфатлар төп мәгънәле тәңгәллекләре белән тәрҗемә ителми, болай эшләгәндә, сәнгатьле тәэсир итми торган ят, сәер бирәмлекләр барлыкка килә. Шулай итеп, чыганак экияттәге сыйфат күчерелмә мәгънәсе чыганак тел чарасыныкы белән бердәй, ләкин икенче образга корылган тәрҗемә теле берәмлеге белән алмаштырыла. Мәсәлән, «Колобок» экиятендә күзәтелгән мисалларны карыйк: Какой ты **хорошенький.** - Син нинди **гүзәл** икән?!; Какая **славная** песенка! – Нинди **яхшы** җыр!

Шулай итеп, экиятләрдәге сыйфатларны тәрҗемә иткәндә, дөрес вариантлар куллану зарур, чөнки балага дөрес булмаган тәгъбирләр өйрәтү тискәре нәтиҗә бирәчәк. Ул әлеге сүзләрне, эпитетларны сөйләмдә ялгыш кулланачак яки экиятнең сюжетын дөрес күзалламаячак. Халык экиятләрен тәрҗемә итү тәрҗемәче алдына үзенчәлекле бурычлар куя: төп нөсхәнең мәгънәсе дөрес бирелергә тиеш; тәрҗемә чит телле укучыга аңлашылырга тиеш.

Төп нөсхәне аңлату чыганак эчтәлеген адекват чагыштыра торган тел чараларын эзләп табу белән генә бәйләнмәгән.Тәрҗемәче ике телне дә камил белүдән тыш, әсәр иҗат ителгән мәдәниятне, көнкүрешне, гореф-гадәтләрне белергә тиеш. Кайвакыт сүзнең синонимын куллану, төшереп калдыру уңышка ирешергә мөмкинлек бирә.

Билгеле булганча, автор стилен саклау – әдәби әсәрне тәрҗемә итүгә куелган төп таләпләрнең берсе. Ә халык экиятләренең стиле - табигать күренешләрен, вакыйга бара торган урынны гади сүз белән генә әйтеп бирү, геройларның тышкы кыяфәтен төгәллек белән җиткерү. Моның өчен, әлбәттә, сыйфатлар куллану зарур. Шунлыктан экиятләрдә һәрвакыт сурәтләү чаралары кулланыла. Тәрҗемәче әнә шул сыйфатларны сакларга, экияттә күрсәтергә теләгән моментларга зыян китермәскә тиеш.

**Литература**

1. Алексеева И.С. Введение в переводоведение / И.С. Алекссева. - М.: Академия. 2004. – 230 с.

2. Җамалетдинов Л.  Әкиятләрнең кайбер поэтик үзенчәлекләре // Фольклор теле – шигърият теле. -  Казан: Фикер, 2001. – Б. 45.
3. Русские народные сказки. – Казань: Тат. книг. издат., 1985. – 384 с.
4. Татар халык әкиятләре.  - Казан: Татар. Кит. Нәшр. – 1995. – 345 б.
5. Юсупов Р.А. Соотношение разноструктурных языков и вопросы перевода. – Казань: КГПУ, 2005. – 225с.